# Яз килә

Көннәр аяз, күктә алсу
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы –
Сагынып көткән яз килә.

Әйтегезче,кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк.

Көннәр җылы, күктә алсу
Нур сибеп кояш көлә,
Җәйге шатлык, көзге бәхет
Яз белән бергә (М.Мазунов)

# Табышмаклар

**Иртә килә, кич кайта. *(Кояш)***

**Лампа түгел – яктырта, мич түгел – җылыта. *(Кояш*)**

**Үзе урак, үзе тешсез.  *(Ай)***

**Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач. *(Йолдызлар һәм ай)***

**Аяксыз, кулсыз, капка ача. *(Җил)***

**Агач бөгә – кулы юк, йөри торган юлы юк. Ачуланса – сызгыра, тузаннарны туздыра. *(Җил)***

**Аягы юк, кулы юк, үзе сүрәт төшерә. (*Суык*)**

**Кулсыз, күзсез, буяусыз ясый ул төрле бизәк.**

**Беркем аны өйрәтми, ул үзе шундый зирәк. (*Суык)***

**Утта янмый, суда батмый. (*Боз*)**

**Борынсыз чыпчык боз тишә. (*Тамчы*)**

**“Күктән килде, җиргә иңде” (*Болыт, яңгыр)***

**“Ак ашьяулык таптым, җир өстенә яптым” (*Кар)***

**Канатсыз, йонсыз нәрсә оча. *(Кар*)**

**Исе юк, төсе юк, аннан башка тормыш юк. (*Су*)**

# ХАЛЫК СЫНАМЫШЛАРЫ

**Яз көне эретмичә озак тундырып торса, җәй коры була.**

**Яз көне агачлар бөреләрен астан яра башласа, яз тиз килә.**

**Кара карга килгәч, бер айдан кар кар китәр.**

**Карлыгач иртә килсә, көннәр тиз матурланыр.**

**Елгалар язын боздан тиз әрчелсә, ашлык уңар.**

**Су ташуы куәтле булса, ашлык яхшы булыр.**

**Язын иртә күк күкрәсә, ел яңгырлы булыр.**

**Аккош яз көне иртә күренсә, салкын булыр, кар тиз китмәс.**

**Язын сыерчык иртә килсә, көннәр җылы булыр.**

**Яз көне хайван аяк эзләре эресә, җылытыр.**

**Черкиләр яз көне иртә күренсәләр, һава җылыныр.**

**Апрель актыкларында җылы яңгырлар булса, игеннәр яхшы булыр.**

**Апрель алтысында аяз булса, җәй коры килер; болытлы булса, ашлык уңарга булыр.**

**Егерме өченче апрельдә иртә белән чык күп төшсә, карабодай уңар.**

**Яз көне елга кырыйларында боз калса, ашлык уңмас.**

**Яз көне елгаларда су артмаса, ашлык уңмас.**

**Яз көне тамчы бозлары озын булса, сабан ашлыгы озын булыр; әгәр кыска булса, сабан ашлык кыска булыр.**

**Яз көне урамнарда кар элегрәк китсә, карабодай яхшы булыр.**

**Кар барында күк күкрәсә, ашлык булмас.**

**Әгәр карга ябыгып килсә, ашлык уңар.**

**Яз узгэрешлэре**

*Кояш нурлары ныгырак җылыта.*

*Кошлар җылы яклардан кайталар.*

*Карлар эри башлады.*

*Яз – ул табигатьнең уянуы.*

*Җирне, карны тишеп беренче чәчәкләрнең чыгуы, агачларның бөреләнүе, ераклардан туган якларга кошларның кайтуы – болар барысы да яз тавышлары, яз авазлары.*



